**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас**
**авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 ел, 14 ноябрь** **№ 91**

2013 елның 17 нче декабрендәге ""Татарстан
Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Олы Бортас авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге төзелешләре һәм
җирдән файдалану кагыйдәләрен раслау
турында"гы 87 нче номерлы Татарстан
Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Олы Бортас авыл җирлеге Советы
Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге" Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2013 елның 17 нче декабрендәге 87 нче номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының Карары белән расланган "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге" муниципаль берлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 26 маддәдә:

1) 8 пунктның 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10) төзелешкә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга, капиталь төзелеш объектларын сүтүгә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итеп финанслана торган мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр үткәрүгә, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар акчаларына, Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең уставы (оешкан) капиталларындагы өлешенә смета 50 процентан артык тәшкил итә;";

2) 8 пунктның 15 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Проект документларына экспертиза ясау өчен һәм Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарына тапшырыла торган проект документларының

бүлекләренең составына һәм эчтәлегенә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә һәм капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә (шул исәптән линия объектларына) карата, шулай ук Капиталь төзелеш объектларының, эш төрләре (капиталь төзелеш объектларының төзелеше, реконструкцияләнүе, капиталь ремонты), капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә карата дифференциацияләнә, эшләрне финанслау һәм төзелешнең, үзгәртеп коруның аерым этапларын әлеге маддә таләпләренә туры китереп һәм түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып бирү чыганаклары:

1) проект документларын әзерләү капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә (шул исәптән линия объектларына) карата аерым бүлекләр күләмендә, шулай ук, төзүче яисә техник заказчы тарафыннан, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләгәндә башкарыла торган эшләрнең эчтәлегенә карап, проектлауга бирелгән биремнәр нигезендә (капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта) проектлауга йөкләмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла;

2) капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проектында капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проекты булырга тиеш (капиталь төзелеш объектларын, төзелеш өчен аларның өлешләрен, башка капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өчен сүтәргә кирәк булган очракта);

3) проект документларында булган карарлар һәм чаралар мәдәни мирас объектларын саклау турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килергә тиеш (мондый объектларның ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикаларына кагылышлы мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкару өчен проект документлары әзерләнгән очракта);

4) проект документлары “Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтка, сүтүгә смета” бүлеген кертергә тиеш (әгәр төзелеш, реконструкция, юкка чыгару Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, әлеге Кодексның 8.3 маддәсендәге 2 өлешендә күрсәтелгән юридик затлар чараларын җәлеп итеп финансланса, капиталь ремонт Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, әлеге Кодексның 8.3 маддәсендәге 1 өлешендә күрсәтелгән затларның акчаларын җәлеп итеп финанслана);

5) 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы “Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында”гы Федераль законның 14 маддәсендәге 3 пунктында, 1997 елның 21 июлендәге 117-ФЗ номерлы “Гидротехник корылмаларның иминлеге турында”гы Федераль законның 10

маддәсендәге, 1995 елның 21 ноябрендәге 170-ФЗ номерлы “Атом энергиясеннән файдалану турында”гы Федераль законның 30 маддәсендәге, 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы “Мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында”гы Федераль законның 36 маддәсендәге 2 һәм 3 пунктларында каралган очракларда, проект документлары составына федераль законнарда каралган документлар, проект документлары бүлекләре мәҗбүри рәвештә кертелә.”;

3) 8 пунктны түбәндәге эчтәлекле 6.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

“6.1) “Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законда каралган очракларда, юл хәрәкәтен оештыру проекты”;

1.2. 27 маддәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә экспертиза нәтиҗәсе булып инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламент таләпләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында бәяләмә тора. Проект документларына экспертиза нәтиҗәсе булып түбәндәге бәяләмә тора:

1) әлеге маддәнең 5 өлешендәге 1 пунктында каралган таләпләргә (әлеге маддәнең 3.3 өлешендәге 1 пункты нигезендә проект документларына экспертиза үткәрү очракларыннан тыш), әлеге маддәнең 5 өлешендәге 1 пунктында каралган таләпләргә туры килү (уңай бәяләмә) яисә инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, проектлау өчен бирем, проект документларына туры килмәү (тискәре бәяләмә) турында;

2) Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсендәге 2 өлешендә билгеләнгән очракларда капиталь төзелеш объектлары төзелешенең смета бәясен билгеләүнең дөреслеге (уңай бәяләмә) яисә дөрес булмавы (тискәре бәяләмә) турында.”;

1.3. 27 маддәнең 4 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләти экспертиза оештыру һәм үткәрү, проект документларына дәүләти булмаган экспертиза һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләти булмаган экспертиза үткәрү тәртибе, проект документларына дәүләт экспертизасы һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү күләме, бу түләүне алу тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.”;

1.4. 29 маддәдә:

1) 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) Капиталь төзелеш объектын кабул итү акты (төзелеш подряды килешүе нигезендә төзелеш, реконструкция гамәлгә ашырылган очракта);”;

2) 3 пунктның 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

3) 3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документларының параметрларының, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килүен раслый торган акт һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат (төзүне башкаручы зат һәм төзүче яисә техник заказчы тарафыннан төзелгән, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырган очракта, төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырган очракта, шулай ук төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзаланган, килешү нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыру очрагында);”;

4) 3 пунктның 8 пунктчасында “шартнамәне” сүзен “төзелеш подряды килешүен” сүзләренә алмаштырырга”;

5) 3 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турындагы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе (Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 54 маддәсенең 1 өлеше нигезендә Дәүләт төзелешен күзәтүне гамәлгә ашыру каралган очракта), Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 54 маддәсенең 7 өлешендә каралган очракларда бирелә торган башкарма хакимиятнең федераль органының федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле бәяләмәсе;”;

6) 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 10 пунктчасы белән тулыландырыга:

“10) 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы “Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында”гы Федераль закон нигезендә әзерләнгән капиталь төзелеш объектының техник планы”;”;

7) 4 пунктта “ун көн” сүзләрен “җиде эш көне” сүзләренә алмаштырырга”;

8) 7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Объектны файдалануга тапшыру рөхсәтендә капиталь төзелеш объекты турындагы дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә мәгълүматлар чагылдырылырга тиеш. Мондый мәгълүматларның составы 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы “Күчемсез милекне дәүләт

теркәве турында” гы Федераль закон нигезендә техник планның график һәм текст өлешләрендәге мәгълүматлар составына куелган таләпләргә туры килергә тиеш.”;

9) 29 маддәнең 5 пунктындагы 6 абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 30 маддәнең 8 пунктын “Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрын, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган белешмәләр, документлар һәм материалларга мәгълүматларына” сүзләре белән тулыландырырга”;

2. Әлеге Карарның 1.1 өлешенең 3 пункты 2018 елның 30 декабреннән, 1.2 өлеш, 1.4 өлешенең 9 пункты - 2019 елның 1 гыйнварыннан, 1.1 өлешенең 2 пункты – 2019 елның 1 июленнән законлы көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Бортас авылы, Ленинград урамы, 27;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балчыклы авылы, Ленин урамы, 70,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Олы Бортас авыл җирлеге**
**Башлыгы, Татарстан Республикасы**
**Олы Бортас авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Р.С. Сәгдиев**